СОВЕТ ЛЕВАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕВАШЕВОАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с. Левашево

17.11.2023 № 55

**Левашево авыл җирлеге Советының**
**15.11.2018 ел, №91 «Җир салымы турында»**
**карарынаүзгәрешләркертүхакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенеңаерым закон актларынаүзгәрешләркертүһәм Россия ФедерациясеСалымкодексыныңберенчеөлешендәге 78 статьясының 1 пунктындагыикенчеабзацыныңгамәлдәбулуынтуктатып тору турында»2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законгаярашлырәвештәһәмАлексеевск районы прокуратураысының 19.10.2023 елдан №02-08-01-2023 протестын карап чыгып

**Левашево авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге Советының 15.11.2018 ел, № 91«Җир салымы турында» карарының 2пунктының 2 пунктчасы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-торак фонды һәм (яисә) торак - коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары тарафыннан биләнгән(торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);».

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Левашево авыл җирлеге башлыгы** **С.А. Демидова**